# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Сахаровка авыл җирлеге составына керүче
Речное авылы торак пунктында

2020 елның 11 ноябре

№ 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлеге составына керүче Речное авылы торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда Сахаровка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, гражданнарның үзара салымын 1000 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:

- Авыл эчендәге юлларны төзекләндерү (вак ташны сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча түләү);
- Вак таш җәелгән юлларны ремонтлау (вак ташны сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Җәйге чорда грейдерлау һәм үләнне чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Авыл эчендәге юлларны кышкы чорда чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Авыл җирлегенең торак пунктында урамнарны яктырту (урам фонарьлары, исәпкә алу приборлары, таймерлар сатып алу, СИП үткәрү, килешү буенча хезмәт өчен түләү);
- Артезиан скважиналары өчен су асты насосы сатып алу (насос сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Контейнерлар сатып алу (контейнерлар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Әлеге карарны Сахаровка авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Сахаровка авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Сахаровка авыл җирлеге башлыгы Л.В.Шаброва